СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

22 гыйнвар, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 7 (8019) | Бәясе билгеләнгәнчә

### 30 мартта - Татарстан Дәүләт Советына өстәмә сайлаулар

## ДЕПУТАТЛЫККА КАНДИДАТ КҮРСӘТЕЛДЕ

***20 гыйнварда «Норлат шикәр заводы» АҖ клубында сайлаучыларның 50 нче Октябрь административ-территориаль округы буенча Татарстан Республикасы халык депутатлыгына кандидат күрсәтүгә багышланган җыелышы булды. Анда катнашкан эшчеләр, хезмәткәрләр, инженер - техник работниклар, ветераннар һәм яшьләр - 150дән артык кешенең барысы да завод директоры А.К.Савиновның Татарстан Республикасы халык депутатлыгына кандидат итеп район хакимияте башлыгы Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллинны күрсәтү турындагы тәкъдимен бертавыштан якладылар. Завод директоры урынбасары Н.М.Шәйхиев, баш технолог Р.М.Бикмурзина һәм башкаларның чыгышларында сайлаучыларның Ф.С.Сибагатуллинның эшлекле гамәлләре белән район халкының тормыш шартларын яхшырту, аерым алганда газлаштыру, су белән ышанычлы тәэмин итү, Каравыл Тавы янында яңа күпер салу кебек перспектив һәм агымдагы чараларны тормышка ашыра баруын зур канәгатьлек белән билгеләп үтелде һәм тормышыбызның яхшырачагына ныклы ышаныч белдерелде, чөнки моның өчен районда потенциаль мөмкинлекләр булуына басым ясалды.***

***Җыелышта катнашучылар 1997 елның 30 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда Ф.С.Сибагатуллин кандидатурасын бердәм яклаячакларын белдерделәр.***

## Район Советына депутатлыкка кандидат

18 гыйнварда Кузнецов исемендәге КХА сайлаучылары җыелышында 18 нче Егоркино сайлау округы буенча халык депутатларының Октябрь район Советына халык депутатлыгына кандидат итеп Норлат разведка бораулавы идарәсе начальнигы Анатолий Степанович Насолдин күрсәтелде. Очрашуда катнашучылар эре нефть разведкалау коллективы җитәкчесе, зур тормыш һәм профессиональ тәҗрибәсе булган кешенең район Советында үзләренең ышанычлы вәкилләре буласына һәм авыл халкы ихтыяҗларын аңлаячагына ышануларын белдерделәр.

## Рәсми хроника

18 гыйнвар көнне Кузнецов исемендәге крестьян хуҗалыклары ассоциациясе членнарының гомуми җыелышы булды. Җыелыш КХА рәисе Анатолий Николаевич Яковлевны шәхси гаризасы нигезендә эштән азат итте. Кузнецов исемендәге КХА рәисе итеп Евгений Владимирович Абрамов сайланды.

Җыелышта район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев һәм халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары Е.К.Савинов катнаштылар.

*Номерга хат*

## ГАЗ БЕЛӘН ҖЫЛЫТЫЛА

Шәһәрнең тимер юлчылар поселогындагы мәчеткә йөрүчеләрнең бу көннәрдә шатлыгы бик зур - мәчетне газ ягып җылытуга күчерү эшләре төгәлләнде. Моңа кадәр мәчетне җылыткан өчен тимер юлчыларга елына 10 миллионнан күбрәк сум акча күчереп барырга туры килә, ә ул бик авырлык белән табыла иде. Шуңа да узган җомга көн мәчетне газ ягып җылытуга күчерү тантанасы бу микрорайон мөселманнары өчен чын бәйрәмгә әверелде. Тантанада район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин, аның төзелеш эшләре буенча урынбасары Н.Б.Мөлеков, Норлат җирле үзидарә Советы рәисе Ф.И.Гайнуллин катнаштылар. Без, картлар, газга күчерү эшен тизләткәннәре өчен дә, безнең шатлыгыбызны уртаклашырга килгәннәре өчен дә җитәкчеләргә чын күңелдән рәхмәт укыйбыз. Ф.С.Сибагатуллинның безнең сорауларыбызга биргән җавапларын да зур канәгатьлек белән тыңладык. Районның яңа җитәкчелеге халыкның тормыш хәлен яхшырту өчен конкрет чаралар күрә, алга таба тагын да зуррак эшләр ниятли икән.

Аларга изге эшләрендә ходай исәнлек бирсен.

**Шушы мәчеткә йөрүче мөселманнар исеменнән Р.Рәхмәтуллин.**


## КИҢӘШМӘДӘ - ТЕХНИКА ХӘЗЕРЛЕГЕ МӘСЬӘЛӘСЕ

Яз тау артында түгел. Ә бер көн ел туйдырырлык яз. ы көннәрдә югары нәтиҗәле эшләү өчен бүгеннән хәзерләнергә кирәк. Узган җомгада Хафизов исемендәге КФХА базасында район хакимияте, авыл хуҗалыгы идарәсе җаваплы хезмәткәрләре, авылда ярдәмче хуҗалыклары булган промышленность предприятиеләре, крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциацияләре җитәкчеләре, соңгыларының баш инженер - механиклары катнашында үткән семинар - киңәшмәдә төп игътибар шуңа юнәлдерелде. Анда катнашучылар хуҗалыкның үзәк ремонт мастерскоенда, гаражында булып, ассоциациядә чәчүдә катнашачак барлык төр техника, авыл хуҗалыгы машиналарын төзәтүнең барышы, моның өчен тудырылган шартлар белән якыннан таныштылар. Шунда ук машина төзү заводында эшләнгән КФН - 8 маркалы культиватор, минераль ашламалар төяү агрегатын карадылар. Соңгысы турында семинар - киңәшмәдә сүз аеруча җитди булды. Ни өчен дигәндә, иске РМГ - 4, РУМ - 3, МВУ - 6 маркалы ашлама тараткыч агрегатларны реконструкциялəп ясалган шнеклы бу җайланмаларның ашламаларны чәчкечләргә төяүдә өстенлеге бәхәссез. Семинар - киңәшмә эшенә җитәкчелек иткән район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да анда катнашучылардан эре һәр хуҗалыкта өчәр, вагракларында икешәр шундый төягеч булдыруны катгый таләп итте.

Семинар - киңәшмәдә техника, аны нәтиҗәле файдалану, шулай итеп эксплуатацияләү срогын арттыру, моның өчен аңа барлык техник карауларны вакытында үткәрү зарурилыгы турында да җитди сөйләшү булды.

Семинар - киңәшмәнең икенче өлеше хуҗалык идарәсенең кече залында үтте. Анда чыгыш ясаган район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин районның бүгенге тормышының байтак мәсьәләләренә тукталып, күтәрелгән һәр проблема буенча җитди анализ ясады, сүзләрен саннар, фактлар белән дәлилләде. Һәр җитәкче, белгечнең үз хезмәте өчен шәхси җаваплылыгы, барлык тармакларда аз чыгымнар тотып күп продукция җитештерү, хезмәт хакының җитештерелгән продукция, ахыргы нәтиҗәгә бәйлелеге - шуларның берничәсе. Болардан тыш, Фатыйх Сәүбәнович авыл хуҗалыгы ассоциацияләрендә минераль ашламалар белән җитди эшләү кирәклеген дә ассызыклады.

**Рәсемнәрдә: семинар - киңәшмәдән күренешләр.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**





## Минтимер Шәрипович Шәймиевка - 60 яшь



**20 гыйнварда Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевка 60 яшь тулды.**

Илбашыбызның юбилее Татарстан Дәүләт Советының чираттагы пленар сессиясе ачылган көнгә туры килде һәм юбилярны котларга сессиягә мәртәбәле кунаклар килде.

Татарстан Дәүләт Советы исеменнән М.Ш.Шәймиевны Дәүләт Советы Рәисе, Федерация Советы Рәисе урынбасары В.И.Лихачев кайнар котлады.

Россия Президенты аппараты җитәкчесе А.Б.Чубайс Минтимер Шәриповичка Б.Н.Ельцинның котлау хатын тапшырды һәм аны Россия дәүләтчелеген үстерүдәге, халыклар арасындагы дуслыкны ныгытудагы казанышлары өчен II дәрәҗәсе «Ватан алдындагы хезмәтләр өчен» ордены белән бүләкләү турында Указын игълан итте.

Россия хөкүмәте җитәкчесе исеменнән чыгыш ясаган беренче вице - премьер В.В.Илюшин Минтимер Шәриповичка Хөкүмәтнең мактау грамотасын тапшырды.

Республиканың башкарма органнары, хакимият башлыклары исеменнән Президентны Татарстан Премьер - министры Ф.Х.Мөхәммәтшин кайнар котлады.

Тугандаш Башкортостан Республикасы Президенты Мортаза Рәхимов Минтимер Шәриповичка ихлас котлау сүзләрен һәм җылы теләкләрен ике телдә дә һәм шигырь юллары белән җиткерде.

Котлауларга җавап сүзе белән чыккан Минтимер Шәрипович Шәймиев чын күңелдән рәхмәт белдерде.

Нәкъ менә бабасының 60 яше тулган көнгә аны сөендереп Президентның тагын бер оныгы дөньяга килде.

## *Район хакимиятендә*

Район хакимиятендә шәһәр предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләре катнашында киңәшмә үткәрелде. Аны район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев алып барды.

Киңәшмәдә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре слетына әзерлек мәсьәләләре буенча район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова чыгыш ясады. Ул авыл хуҗалыгы һәм агропромышленность комплексы хезмәткәрләренең һәр тармактагы алдынгылары өчен үткәреләчәк слетның чаралар программасы белән таныштырды. Шунда ук һәр предприятиегә слетны мөмкин булганча кызыклырак һәм эчтәлеклерәк үткәрү буенча аерым - аерым бурычлар йөкләнде.

Район пенсия фонды рәисе В.Г.Хоменко үзенең чыгышында предприятиеләрнең район пенсия фондына үткән елгы бурычлары түләнеп бетмәвен хәбәр итте. Аның әйтүенчә, 1996 елда пенсионерларга түләнәсе сумма 52 миллиард сумны тәшкил итә, ә предприятие, оешма һәм хуҗалыклардан бу сумманың 73 проценты гына җыеп алынган. Шул сәбәпле халыкка пенсия таратуда тоткарлыклар килеп чыга,- ди ул.

## *Иң зур отыш - Илшатта*

Норлат - Октябрь Агропромбанкында Яңа ел алдыннан акча - әйбер лотореясы сатылды. 27 декабрьдә лоторея уйнатылды, бәхетле отыш ияләре мәгълүм булды. Иң зур отыш - 690 мең сумлык кухня комбайны «НорлаткамАЗсервис» чикле җаваплылыктагы җәмгыятьнең баш бухгалтеры Илшат Гыйззәтуллинга насыйп булды.

Газетабызда нефтьчеләрнең «Зорька» сөт - май комбинаты ачылуы турында хәбәр иткән идек. Инде хәзер комбинатта эшләр ничек тора соң? Шул турыда кызыксынып без комбинат директоры С.В.ӘЮПОВка мөрәҗәгать иттек.

# Канат чыгарганда

Базар

- Алты ай оештыру чоры өчен зур срок түгел. Инде ул тәмамланып килә дип әйтсәм дөресрәк булыр, мөгаен,- дип каршылады безне комбинат җитәкчесе С.В.Әюпов. - Испан технологиясен безнең шартларда эшләрлек, бу процесс белән безнең кешеләр идарә итәрлек итеп яраклаштыру җиңел түгел.

Шулай билгеле. Ярый әле янәшәдә Норлат сөт - май комбинаты бар. Тегe яки бу төрле чатаклык килеп туганда, ярдәм сорап шуларга ашыгалар. Ә тегеләре квалификацияле ярдәмне күрсәтмичә калганнары юк, хәтта биредәге кадрлар да «өлкән» заводта эшләп, бай тәҗрибә туплаган кешеләр. Әнә, технолог, Рәисә Шиһабетдинова карамагында күпмә вазифа бүген: производствоны алып бару, сыйфат мәсьәләләре тулысынча аның өстендә. Май язучы Вера Рыжакны әйт тагын! Тулы бер процесс өчен шәхсән җаваплы бит ул. Шөкер, белемнәрен дә, хезмәт һәм тормыш тәҗрибәләрен дә җигәләр алар эшкә. Шундый бер сыр ясаучы да табылса икән...

Ни эшләмәк кирәк, яңа нәрсә һичкайчан җиңел бирелми шул. Әллә комбинат җитәкчесенең үзенә эшкә күнегү җиңел булды дисезме? Сөт продуктлары җитештерү буенча күпме махсус әдәбият укырга, йөз кат ишеткәнче, бер кат күрү яхшырак дип төрдәш предприятиеләре булган Актүбә, Казанга барырга, хәтта күрше республикаларга да чыгарга, чагыштырырга, бәрысын да үлчәүгә салып карарга туры килде. Производствоны җайга салыйм дисәң, шунсыз мөмкин дә түгел шул. Өстәмә рәвештә юнәтелгән җиһазлар да шул максатка хезмәт итә бүген. Әнә, элегрәк сөтне тулысынча аертып бетерергә көче җитми иде комбинатның. Кыйммәт булса да өстәмә сепаратор сатып алынды. Сепарат сөте пастеризаторы, куертылган сөт ясау агрегаты урнаштыргач та, эшнең ахыргы циклына ирешүне күзалларга мөмкин булды. Күптән түгел сатып алынган май төрү җиһазы бу төр продукцияне пакетларга төрелгән килеш сатуга чыгарырга мөмкинлек бирәчәк. Озакламый исә баш (закваска) ясау бүлеге сафка керәчәк. Ул каймак, эремчек, сырга үзенчәлекле тәм бирүгә хезмәт итеп кенә калмыйча, бу төр продуктларны җитештерүне арттыруга да булышачак. Соңгысы өчен парафинлы тышча ясау (парафинер) җиһазы да көн кадагындагы бурыч. Ахыр чиктә, бу санэпидкүзәтү үзәге таләбе дә.

- Һәр башлангычта идарә начальнигы М.Хуҗинның якыннан торып мораль һәм матди ярдәмен тоябыз,- ди директор үзе.

Гомумән, предприятие канатлары, кем әйтмешли чыга - чыга ныгый. Моны дәлилләү өчен «җанлы» мисаллар китерәсе килә. Әлегәчә, комбинат һичнинди планнарсыз эшләде. Коллектив көн саен 800 килограмм - 1 тонна сөт, 120 килограмм май, каймак, сөт өсте озата кибетләргә. Көн саен ОРСның 5 ләп кибете сату итә бу продукция белән. Халык та нефтьчеләр сөте, мае һәм башкалардан канәгать.

- Барлык төр продуктларның фасовкалап сатылуы бик әйбәт,- диде «Нефтьчеләр» кибетендә каймак чиратында торучы Разия ханым Галиева.

- Ә майлары... - дип сүзгә кушылды сатып алучыларның тагын берсе - авылныкыннан аерылмый, аш - су хәзерләү өчен бигрәк әйбәт инде.

Әйе, әле күптән түгел генә биредә куертылган сөт, сыр, эремчек җитештерү үзләштерелгән. Дөрес, әлегәчә продукция тәҗрибә партиясе белән генә чыгарылган. Сертификат та юнәтә алсалар, продуктларны сатуга да чыгару мөмкин булыр иде.

- Ассортиментны төрләндерү безгә апрель аенда план чигенә чыгарга, һәм шулай итеп, тулы көчкә эшли башларга мөмкинлек бирәчәк,- ди директор. Ә бу буш сүз генә түгел: комбинатның соңгы айларда «сикереше» сизелерлек. Әйтик, октябрь аенда комбинатта 28 тонна сөт эшкәртелсә, ноябрьдә ул икеләтә арткан. Декабрьдә исә эшкәртелгән продукция 88 тонна булган. Апрельдә аны 135 тоннага җиткерү күздә тотыла икән. Бу очракта инде комбинат җитәкчелегенә поставщиклар санын да арттырасы булыр (әлегә бирегә сөтне НГДУның «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгы һәм Синдряков исемендәге КФХАдан гына китерәләр. Майлылыгы 4,1 процентка җитә). Аннан инде хезмәт режимын ике сменада оештыру да көн кадагына басачак. Димәк, эшләүчеләр өчен шартлар булдыру да кирәк булачак. Биредә алар хәзер дә начар түгел. Ашханә, ял бүлмәсе, кер юу урыны, душ бүлмәсе - өзлексез производствода мәшгуль булган эшчеләр өчен мөһим бу. Хезмәт шартлары да канәгатьләнерлек.

- Шәһәрдә үз маркабызны булдыру һәм аны һәрчак югары тоту, конкуренция мөмкинлеген күтәрү - коллективның бар тырышлыгы шуңа туплана бүген,- ди Салих Вазыйхович. Ә нефтьчеләрнең үз сүзләрендә нык торуларын беләбез без.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Биш мең еллык ачлык

# Җир кешелек дөньясын туендыра алырмы?

Бүген дөньяда 800 миллион ябык, 500 миллион юан кеше яши. Юаннары - чамадан тыш күп ашаучылар. Тегеләре дә, болары да авырый. Беренчеләре - ябыгудан, икенчеләре - комагайлыктан.

БМО ябык кешеләргә ярдәм итәргә булды. Әмма юаннар исәбенә түгел. Хәзер кешенекен тартып алу модада түгел, ә ярдәм итүчеләр аз. Мәгълүм ки, ач хәлен тук белми.

Ачлык белән ничек көрәшү мәсьәләсен тикшерү өчен Римда БМО халыкара конференция уздырды. Рәсми рәвештә ул Бөтендөнья азык - төлек форумы дип аталды. Анда 173 ил вәкиле катнашты.

БМО якындагы егерме елда ачыгучылар санын икеләтә - 400 миллионга кадәр киметүне үзенең мөһим бурычы дип саный Моны ничек эшләргә - бик үк ачык түгел әле. Кызганычка каршы, Мальтус картның моннан 200 ел әйткән фаразы раслана, халык саны игенчелек продукциясе җитештерүнең артуыннан тизрәк арта.

Соңгы 40 елда чын - чынлап демографик шартлау булды. Җир шарында халык саны ел саен 90 миллион кешегә арта. Киләчәктә тагын да күбрәк булачак. Ә Кытай, Һиндстан һәм башка дәүләтләрдә гаиләне планлаштыру матур теләк кенә булып кала килә. Ә менә туклану продуктларын җитештерүне арттыру ресурслары бетте бугай инде. Фән, ясалма ашламалар, сугару кешелек дөньясына алга таба атлау мөмкинлеге бирде. 1950 елда 631 миллион тонна бөртекле ашлык җитештерелгән булса, 1990 елда 1 миллиард 780 миллион тонна җитештерелде. Шуннан соң нидер булды, уңыш күләме артмый башлады. Былтыр 1 миллиард 780 миллион тонна бөртекле ашлык җыеп алынды, азык - төлек запасы бик аз калды.

Балык тоту белән хәл тагын да начаррак тора. 1950 - 1989 елларда балык тоту 4,5 тапкырга артты: 19 миллион тоннадан 89 миллион тоннага җитте. 1990 елда балык тоту элекке күләмдә калды. Дөнья океанының күп диңгезләре бик нык фәкыйрьләнде. Диңгез ресурсларын бөлгенлеккә төшерүдә бигрәк тә японнар артык «тырышлык куя». Япон балыкчылары үзләренең бик шәп ятьмәләре белән теләсә нинди җан иясен ахыргача сосып алалар.

Римда булып узган форум делегатлары өметсез хәлдән ничек чыгу турында баш ваталар. Ә хәзерге Заирның көнчыгышында дистәләрчә мең кеше ачлыктан чебен кебек кырыла. Андагы бер халык юаннардан сатып алган корал белән икенче бер халыкны яши торган урыннарыннан куып чыгарды. Теге икенче бер халык моннан биш ел элек беренче халык белән шулай кыланган иде. Сугыш тарафыннан хәрәбәләргә әверелгән Әфганстанда да халык ачлыктан кырыла. Аллага шөкер, дөньяда янадан зур сугыш булмады, әмма кечкенә сугышларда да шәһәр - авыллар гына җимерелеп калмый, авыл хуҗалыгы җирләре дә зәгыйфьләнә.

Ачларны туендыру өчен барыннан да элек сугышларны туктатырга, «кайнар нокталар»ны суындырырга кирәктер. Әмма моны ничек эшләргә кирәклеген хәтта Рим Папасы үзе дә белми. Тарихчылар раславынча, Җир шарындагы беренче коточкыч ачлык безнең эрага кадәр 3,5 мең ел элек борынгы Мисырда булган. Балчык елъязмаларда бу теркәлгән. Димәк, кешелек дөньясы бу бәла белән 5 мең елдан артык көрәшә инде.

**(«Российская газета»).**

## Россиянең хәрби даны көннәре

# 27 гыйнвар - Ленинград блокадасын өзгән көн (1944 ел)

«Барбарос» планында Ленинград вермахт гаскәрләре ничек кенә булса да яулап алырга тиешле беренче дәрәҗәдәге объектларның берсе булып торган.

1941 елның көзендә Ленинград янында гадәттән тыш авыр хәл килеп туа. Немец - фашист һәм фин гаскәрләренең бердәм хәрәкәтләре нәтиҗәсендә Ленинградның барлык җир өсте коммуникацияләре өзеклектә кала. Шәһәрнең тарихта тиңе булмаган 900 көнлек блокадасы башлана. 3 миллионлап кеше, шул исәптән 400000 бала, Ленинград һәм Балтыйк флоты гаскәрләре чолганышта кала.

Ленинград блокадасын өзү бурычы Ленинград һәм Волхов фронтларының 1943 елгы гыйнвар операциясе вакытында хәл кылына. Оперция Шлиссельбург - Синявск чыгынтысында уздырыла. Анда совет гаскәрләренә дошманның озакка сузылган ныклы оборонасын өзәргә һәм урманлы - сазлыклы кыен шартларда хәрәкәт итәргә туры килә.

1943 елның 12 гыйнвар иртәсендә совет гаскәрләре авиациянең штурм удары белән дә ныгытылган үтергеч ут ачалар. Аннан 67 нче армия һәм 2 нче удар армия частьлары бер - берсенә таба кузгалалар.

Дошман һәр нокта өчен тырмашып ныклы каршылык күрсәтә. 67 нче һәм 2 нче армия бергәләп дошманның каршылыгын җиде көн буе кире кайтаралар һәм җиңүгә ирешәләр. 18 гыйнварда 1 нче һәм 5 нче эшче поселоклары тирәсендә Ленинград һәм Волхов фронтларының күптән көтелгән очрашуы була һәм көн ахырына Ладога күленең көньяк яры гитлерчылардан азат ителә.


Блокада өзелде! Бу хәбәр совет кешеләрен сөендереп илебезнең барлык почмакларына тарала.

Әмма совет гаскәрләре ачкан коридорның киңлеге 8 -11 километр гына була. Ленинград һаман да дошманның артиллерия һөҗүменә дучар ителгән фронт яны шәһәре булып кала бирә. Немец - фашист гаскәрләре, блокада өзелгәч тә, 1943 ел уенча шәһәрне камалышта тоталар. Гитлер һәм аның штабы әле һаман да Ленинградны кулга төшерергә хыялланалар.

Ленинград, Волхов фронтларының совет гаскәрләре, Ленинград предприятиеләрендәге хезмәт ияләре ул чакта блокаданы тулысынча өзүгә әзерлек алып баралар. Армия генералы Л.А.Говоров җитәкчелегендәге Ленинград фронты гаскәрләре 1944 елның гыйнвар уртасында һөҗүмгә күчәләр. Р.Ф.Трибун җитәкчелегендәге Балтыйк флоты фортлары һәм корабльләре фашистларның ныгытылган позицияләренә тоташтан ут яудыралар.

Бер үк вакытта Волхов һәм 2 нче Балтыйк фронтлары дошманның флангларына һөҗүм итәләр. Өч фронт һәм Балтыйк фронтының яхшы итеп берләшеп һөҗүм итүләре нәтиҗәсендә дошман группировкасы тар - мар китерелә, Ленинградтан 220 -280 километрга читкә алып ташлана һәм шәһәр блокадасы өзелә.

**И.САНДЛЕР.**



# Китапханә буш тормый

3903 өлкән кеше һәм мәктәп баласы - район үзәк китапханәсендә былтыр шул кадәрле укучы теркәлде. Китапханәнең үзенә 1900ләп яңа китап кайтты һәм аның китап фонды бүген 77 меңнән артып китә. Алар арасында төрле катлам укучыларның зәвыгына туры килердәйләре бик күп. Узган ел 3832 килүчегә 83 мең данә китап бирелгән.

Китапханә заллары Яңа елга кергәч тә буш тормый. Биредә эшләүчеләр мөрәҗәгать итүчеләрнең сорауларын канәгатьләндерергә тырышалар - читтән торып укучы студентларга кирәкле дәреслекне юнәтергә булышсалар, оста кулларга «Бурда»ның соңгы санын тәкъдим итәләр.

# КЕШЕ ҺӘМ ЗАКОН

# Районда җинаятьчелек: ел йомгаклары

## Гомуми картина

1996 елда районда 429 җинаять теркәлде һәм бу аннан алдагы елдагыдан 30га кимрәк.

Бер елда тикшерелгән җинаятьләр саны 386, әмма 1995 елдагыдан 3 кә азрак булды. Тикшерелгән җинаятьләрнең ачылышы 87,7 процент булды һәм бу аннан элеккеге елдагыдан 1,5 процентка югарырак.

Авыр җинаятьләр саны 216, ягъни 1995 елдагыдан 67гә азрак булды. 1996 елда 184 авыр җинаять тикшерелеп, шуларның 81,4 проценты ачылды. Бу күрсәткеч 1995 елдагыдан 1,6 процентка югарырак.

Җинаятьләрнең аерым төрләренә килгәндә, хәл түбәндәгечә (саннарның беренче баганасы 1995, икенчесе 1996 елда эшләнгән җинаятьләр саны).

| | | |
|---|---|---|
| Алдан уйланылган үтерүләр | 7 | 12 |
| Алдан уйлап авыр тән җәрәхәте ясау | 8 | 9 |
| Юлбасарларча һөҗүм итү | 4 | 2 |
| Талау | 10 | 5 |
| Көчләү | 1 | 4 |
| Хулиганлык | 70 | 89 |
| 206 нчы маддәнең 2 нче, 3 нче бүлекләре буенча хулиганлык | 61 | 57 |
| Яшерен рәвештә урлау | 209 | 153 |
| Дәүләт милкен урлау | 34 | 30 |
| Автомототранспорт урлау | 4 | 12 |
| Мөлкәткә ут төртү | 7 | 4 |
| Законсыз төстә корал саклау һәм йөртү | 6 | 7 |
| Наркотиклар | 3 | 6 |
| Үтерү белән янау | 20 | 47 |

## Җинаятьләрнең ачылышы

на килгәндә, былтыр белә торып авыр тән җәрәхәтләре ясау, юлбасарларча һөҗүм, талау, хулиганлык, законсыз төстә корал саклау һәм йөртү, наркотиклар буенча тулысынча, алдан уйланылган үтерүләрнең 84,6, шәхси милек урлауларның 73,3, автомототранспорт урлауларның 83,3, мөлкәткә ут төртүләрнең 60, юл - транспорт вакыйгаларының 82,9 проценты ачылды, шулардан шәхси милек урлаудан калганнары буенча күрсәткечләр 1995 елгы дәрәҗәдә яки югарырак.

Икътисад өлкәсендә 35 җинаять ачыкланды. Бу 1995 елдагыдан 1 гә күбрәк. Шуларның 18е урлау, 14е яшертен урлау, 3се алдалап алу. Куллану базары өлкәсендә 89 кеше административ җаваплылыкка тартылды (1995 елда 91 иде).

## Җәмәгать тәртибе

Җәмәгать урыннарында җинаятьчелек очраклары бер елда 50 дән 20гә калды.

Спиртлы эчемлекләр эчкән, җәмәгать урынnarында исерек хәлдә күренгән өчен 1992 кеше административ җаваплылыкка тартылды, бу сан аннан алдагы елдагыдан 80гә күбрәк. Вак хулиганлык өчен 1380 кеше тоткарланды, 234 кеше вак урлаучылык өчен җавапка тартылды. 41 көмешкә куу очрагы ачыкланды һәм бу 1995 елдагыдан 29га азрак. Исерек хәлдә эшләнгән җинаятьләр саны 1995 елдагы 90 урынына былтыр 73 булды.

## Яшьләр арасында җинаятьчелек

Былтыр үсмерләр тарафыннан 29, ягъни 4кә күбрәк җинаять эшләнгән, аларда катнашкан 38 үсмернең 13е исәптә тора, 22се мәктәпләрдә яки ПТУда укый. Беренче һәм икенче мәктәп укучылары арасында җинаятьчелекнең елдан - ел үсүе күзәтелә. 1 нче гыйнварга ОППНда 192 үсмер һәм 48 гаилә исәптә тора.

467 үсмер төрлечә хокук бозулар өчен, шулардан 241е җәмәгать урыннарында исерек хәлдә күренүләре, 4се наркотик матдәләр кулланганнары, 93е вак хулиганлык өчен район эчке эшләр бүлегенә китерелде.

## Паспорт - виза службасы

1996 елда 1533 паспорт бирелгән, шуның 141е - элеккесен югалтучыларга. Паспорт режимын бозган 457 кеше ачыкланган.

**Район эчке эшләр бүлеге штабы.**

# ХӘРӘКӘТ БӘРӘКӘТЛЕ ГЕНӘ БУЛСЫН

Былтыр район территориясендә 39 юл - транспорт вакыйгасы булып, аларда 12 кеше үлде һәм 37 кеше яраланды. 1995 ел белән чагыштырганда бу күрсәткечләрнең өчесе дә кими төште.

Дүрт, ягъни һәр алтынчы юл - транспорт вакыйгасы исерек шоферлар гаебе белән килеп чыкты. Әйтик, 12 сентябрьдә 10 нчы НГЧ шоферы Николькин тайгак юлда борылганда идарә итә алмыйча машинасы канауга төшеп каплана, нәтиҗәдә машинадагы пассажирлардан А.Изратов үлә, ә Р.Биктимеровтән җәрәхәтләре белән шифаханәгә китерелә. 5 октябрьдә В.Малинин МТЗ - 80 тракторында үр менгәндә канауга каплана һәм җәрәхәтләреннән урында үлә. 6 ноябрьдә А.Алексеев үз автомобилендә Норлат - Аксумла юлының 10 нчы километрында тизлекне арттыра һәм каршы хәрәкәт полосасына чыгып каплана, фаҗига үлемгә китерә. 8 ноябрьдә И. Яруллин аек булмаган хәлдә Кычыткалыдан Колбай Морасага таба барганда каршы хәрәкәт полосасына чыгып өч җәяүлене таптата, шуларның икесе үлә, берсе авыр тән җәрәхәте ала.

Гәрчә районда рульдәгеләрнең исерек хәлдә булуы аркасында ясалган юл - транспорт вакыйгалары артмаса да, кайбер коллективларда профилактика эше һаман да тиешле дәрәҗәдә түгел әле.

Былтыр юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган 13000 кеше теркәлеп, аларның 900дән күбрәге исерек хәлдә иде. Андыйлар арасында НУРБдан 33, УТТдан 28, шикәр заводыннан 14, «Агрохимсервис» АҖнән һәм МСО АТПсыннан 13 әр, «Сельхозтехника»дан 12, ДРСУдан 10 кеше булды.

Узган ел меңярымнан артык транспорт берәмлеге ГАИның штрафлы саклау урынына ябылды. Хәзерге вакытта анда ияләре түләп алудан баш тарткан 70тән күбрәк техника бар. Алар сәүдә предприятиеләре аркылы сатылачак, акчасы район бюджетына керәчәк һәм ГАИның матди хәлен ныгытуга тотылачак.

Бүгенге көндә районда ун меңнән күбрәк автомототранспорт чарасы исәпләнсә дә, хәзергә кадәр автомобильләргә капиталь ремонт үткәрүче автосервис һәм диагностика станциясе булмау сәбәпле машина ияләре буяту яки җитди ремонт ясату өчен башка районнарга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрләр.

Хәрәкәт куркынычсызлыгы автомобиль юлларының торышына да бик нык бәйле. Былтыр гына да юлларга 100 билге куелды һәм хәзер район эчендәге юлларда 500 билге, 54 күрсәткеч, дүрт светофор бар. Билгеле, болар гына җитәрлек түгел әле һәм финанс мәсьәләсен хәл иткәндә юл билгеләрен шактый арттыру сорала.

Районда пассажирлар ташкыны да ишле. Былтыр шәһәрара 7, шәһәртирә һәм шәһәр эчендәге 7 маршрутта 1 миллион 300 мең пассажир йөргән. Бәхеткә каршы, автобуслар катнашында юл - транспорт вакыйгалары булмады. Әмма моннан чыгып кына тынычланырга кирәкми, чөнки пассажир транспорты эшен оештырудагы җитешсезлекләр ачык билгеле, алар иң элек тиешле диагностика службасы булмауга бәйле. Юлларда балалар үлеме булмау да тынычландырырга тиеш түгел, чөнки узган ел алар катнашында 4 юл - транспорт вакыйгасы булып, дүрт бала җәрәхәтләнү барыбер уйландырырга тиеш.

Кыскасы, ел йомгаклары гыйбрәтле дә, уйландырырлык та. Һәм яна елны юл хәрәкәте мәсьәләсендә алдагысыннан иминрәк итү өчен барыбызга да игътибарлырак булу сорала.

**М.ӘЮПОВ,**
**ГАИ бүлеге начальнигы, милиция майоры.**



Теләсә нинди һава шартларында юллардагы тәртип сагында торучылар кемнәр дисәк, алар дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре булыр. Аларның юлда тәртип саклау, үткән машиналарны тикшерүдән башка эше дә юк кебек. Ләкин ул алай түгел. Адашканга, ялгышканга юл күрсәтүче, бәхетсезлеккә таручыга ярдәм кулы сузучы, ә кайара җинаятьче белән күзгә - күз очрашучы да бит алар. Зәкиулла Фәтхуллович та инспекциядә эшләү чорында әллә нинди хәлләр белән очрашып, кеше күз алдына да китерә алмаслык ситуацияләргә юлыкканы бар. Ә аның ГАИга эшкә килүенә ике дистә ел инде. Башта гади инспектор иде, бернинчә елдан юл - патруль хезмәте өлкән дәүләт автоинспекторы.

- Чин үзгәрсә дә, ГАИда эшләүче өчен иң мөһим нәрсә юлдыр инде, - дим капитан Хөснуллинга.

- Әйе, без юлаучыларның берсенә дә начарлык теләмибез. Юл хәвефсезлеге, җинаятьчелеккә каршы көрәш - иң мөһиме инде. Беренчедән, руль артына утырган һәр кеше аек һәм аның транспорт йөртү хокукы булырга, һәр транспорт тәртиптә тотылырга тиеш. Ә хәзер эш спецификам үзгәрәк...

Өлкән дәүләт автоинспекторының төп вазифасы - техника күзәтчелеге. Автотранспорты булган оешмалардагы техниканың гараждан төзек килеш кенә чыгарылып җибәрелүе, шоферларга медицина тикшерүе үткәрү - аның вазифасына керә торган төп вазифалар болар. Ә көндәлек вак - төяге, кәгазь эше күпме тагын?!

Көн дәвамында күпме шоферлар белән очрашып, кайсын кисәтергә, икенче берсен шелтәләргә туры килә аңа. Хәер, аның тавык чүпләп бетерә алмаслык эшен санап чыгу да мөмкин булмас иде хәтта. Зәкиулла Фәтхуллович исә үз вазифасын һәрчак җиренә җиткереп үти, һәрвакыт төгәл булырга, намусына хыянәт итмәскә омтыла.

**Р.МИНАПОВА.**

**Рәсемдә: З.Хөснуллин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Шоферлар 30 га артты

**Узган атнада район - оборона - спорт - техника оешмасы каршындагы автомобиль йөртүчеләр хәзерләү курсларында укучылар имтихан тоттылар.**

Юл йөрү кагыйдәләренең катлаулана, шул сәбәпле имтихан алучыларның да таләпләре каттыйлана баруга да карамастан, «ВС» категориясе группасындагы барлык 30 укучы да имтиханнарын уңышлы тапшырдылар һәм автосөючеләр, шул ук вакытта профессиональ шофер булып эшләүгә хокук бирүче таныклыкларга ия булдылар.

**Ф.Курамшина.**

## *Булмас димә, дөнья бу!*

### Ком ашап туена

Кемнәрдер иртән бер чынаяк кофе эчмәсә яки көндезге аш вакытында бер кисәк ит ашамаса, үзен «кеше» итеп сизми. Ә менә 70 яшьлек Хәҗәр Амма күршедәге төзелеш мәйданыннан казып алынган... бер килограмм ком ашамаса, кәефсезләнә, ашказаны авырта башлый. Һиндистанның Җамнагар шәһәрендә яшәүче бу ханым ком ашауга 60 еллар элек ияләшкән. Бу гадәтеннән биздереп булмагач, аны ире дә ташлап китә. Хәзер Хәҗәрнең өч кызы да үлеп беткән. «Минем ком ашавымнан җирәнмәгән булсалар, яши иде әле алар», - ди ул үзе. Бер карасаң, аннан бер дә чиркана торган түгел. Хәҗәр комны башта бик яхшылап иләк аша үткәрә, кат - кат юа, аннары полиэтилен пакетка салып гел үзе белән йөртә: ашыйсы килә башласа, каба да җибәрә. Табиблар аның ашкайнату органнарын, арт юлларын җентекләп тикшергәннәр, бернинди тайпылыш юк, тәрәте дә нормаль.

### «Кызыл борын»

Яңа ел көннәрендә Канаданың Квебек шәһәрендә 10 елдан артык инде кызыклы чара үткәрелә. Бу чараның максаты бәйрәмдә «каты» эчемлек зәһәрләгенә бирешкән кешеләрне өйләренә кайтарып тапшырудан гыйбарәт.

Полиция тарафыннан билгеләнгән залга кичләрен җыела торган миһербанлы затларга кытлык юк. Телефон шалтыраганчыга хәтле алар үз эше белән мәшгуль. Ә инде кунаклы йорттан, рестораннан яисә сыра залыннан хәбәр алынган миһербан иясе үз машинасы белән шунда китә һәм артык кәефләнгән бәндәне өенә илтә. Исерекне үз машинасында кайтарып кую очраклары да була. Иң мөһиме: алкоголь белән башы томаланган кеше руль тотмасын. «Кызыл борын» операциясе - бәйрәмне хәвефсез һәм рәнҗүләрсез үткәрүдә иң әйбәт чара, диләр полициядә.

### Кыскача

Гиннес рекордлары китабы белгечләре яңа өйләнгән иң карт кеше - инглиз Джордж Джеймсон, диләр. 102 яшьлек бу джентельмен 53 яшьлек укытучы Юлия Робенсонга өйләнгән. Юлия үзенең ирен иң әйбәт, иң күркәм, иң кызык кеше дип саный. «Мин канәгать, минем Джорджым чын мәгънәсендә яхшы ир» дип җавап бирә ул барысын да белергә теләүчеләргә.

**• *Салым инспекциясе искәртә***

# АКЧА ТАПСАҢ, БҮЛЕШЕРГӘ ОНЫТМА

| Ел дәвамында алынган барлык керем | Салым күләме |
|---|---|
| 12000000 сумга кадәр | 12 процент |
| 12000001 сумнан 24000000 сумга | 1440000 сум + 12000000 сумнан тыш кергән акчаның 20 проценты |
| 24000001 сумнан 36000000 сумга кадәр | 3840000 сум + 24000000 сумнан тыш кергән акчаның 25 проценты |
| 36000001 сумнан 48000000 сумга кадәр | 6840000 сум + 36000000 сумнан тыш кергән акчаның 30 проценты |
| 48000001 сумнан күбрәк | 10440000 сум + 48000000 сумнан тыш кергән акчаның 35 проценты. |

**Гражданнар 1996 елда алган керемнәре турындагы декларацияләрен 1997 елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча салым инспекциясенә тапшырырга тиешләр. Әлеге сроктан узган физик шәхесләрне салым инспекциясе 2 - 5 айлык минималь хезмәт хакы күләмендә штрафка тартырга мәҗбүр булачак.**

Яңа ел башланды. 1996 елда алган керемнәр турында салым органнарына декларация бирер вакыт. Әлеге декларацияләрне, исәп - хисап елында төп хезмәт урыны булган һәм шул чорда төп хезмәтеннән тыш керем алган, шулай ук төп хезмәт урыны булмыйча, башка чыганаклардан керемнәр алган физик шәхесләр бирә. Декларация салым органнарына, әгәр 1996 елда төрле чыганаклардан алынган (төп хезмәт урынын да исәпкә алып) керем 12 миллион сумнан арткан очракта гына тапшырыла.

Әгәр физик шәхесләр ел дәвамында керемне (теләсә нинди күләмдә) бары тик төп хезмәт урыннарыннан гына алганнар һәм аларга башка керемнәр кермәгән икән, ул вакытта үз керемнәрең турындагы декларацияне салым инспекциясенә тапшыру мәҗбүри түгел.

Декларацияләрне төгәл тутыру максатында алынган керемнәрне үзлегеңнән ел дәвамында теркәп бару урынлы. Мәсәлән, куен дәфтәренә керемнең каян, күпме күләмдә алынганын һәм шул керемнән күпме салым тотып калынганлыгын күрсәтәсең.

Керем турындагы декларацияләрне тутыру буенча тулырак мәгълүматларны яшәү урыннарындагы салым инспекцияләреннән алырга мөмкин. Декларация кәгазе (бланк) бушлай бирелә.

Салым түләүче исәп - хисапны түбәндәге таблицадан файдаланып үзе дә башкарырга мөмкин.

**Татарстан Республикасы Дәүләт салым инспекциясе.**

# МӘКТӘПЛӘРДӘ ЛЕКТОРИЙЛАР БАШЛАНДЫ



**Агымдагы атнадан район белем бирү учреждениеләрендә балигъ булмаганнар арасында негатив күренешләрне профилактикалау буенча лекторийлар башлана.**

Соңгы вакытта балигъ булмаганнар арасында җинаятьнең кискен артуы нәтиҗәсе шундый чара үткәрүне таләп итте. Район хакимияте башлыгы тарафыннан расланган лекторийны нәтиҗәле итеп үткәрергә планлаштыра. Лекторийның беренче занятиесе 99 нчы профессиональ техник училищеда үтте. Анда район эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар җинаятьләрен кисәтү (ОППН) бүлеге хезмәткәрләре, район үзәк шифаханәсенең наркология табибы, район мәгариф бүлеге педагоглары катнашты. Ике ай дәвамында шундый лекторийлар шәһәребезнең барлык мәктәпләрендә, шулай ук үсмерләр җинаятьләре фактлары арткан Яңа Иглай, Якушкино, Мамык мәктәпләрендә дә үтәчәк. Соңрак мәктәпләрдә ата - аналар җыеннары, һәм җыелышлары уздыру планлаштырыла.

Бер үк вакытта балигъ булмаганнар арасында негатив күренешләр проблемаларын индивидуаль өйрәнү һәм ярдәм күрсәтү буенча үзәк шифаханә табибларының мәктәпләргә чыгуы оештырыла.

# Бал һәм үләннәр белән дәвалану




***САЛКЫН ТИГӘНДӘ.*** Ачы тырманы вак кыргыч аша чыгарып, марляга салыгыз һәм шуның белән йоклар алдыннан салкын тигән кешенен тәнен ышкыгыз. Аннары ярты стакан ачы тырма согы эчереп, бик әйбәтләп төреп яткырыгыз, 1 аш кашыгы балны ярты стакан кайнар суда эретеп, бераз суына төшкәч, шуңа ачы тырма согы кушыгыз. Мондый катнашманы әкренләп кенә эчеп җибәрсәң, авыру көчәеп китмәсен өчен файдалы булачак.

***ГРИПП.*** Вак кыргыч аша сарымсак уып, шуңа бал (1:1) кушыгыз. Аннары шуны көнгә 1 - 2 тапкыр берәр аш кашыгы җылы су кушып эчегез. Йокы алдыннан эчү бигрәк тә файдалы.

***ЙӨТКЕРҮ.*** Бер чәй кашыгы балга 2 аш кашыгы әнис орлыгы яки аз гына тоз сибегез. Шуның өстенә бер стакан су салып кайнатып алыгыз һәм саркытыгыз. Шул суны һәр ике сәгать саен икешәр аш кашыгы эчеп торыгыз. Кече яшьтәге балаларга бал белән зәйтүн мае (1:1) кушылмасы эчертү бик әйбәт. Аны көнгә берничә тапкыр эчертергә кирәк.

***ОЗАККА СУЗЫЛГАН ЮТӘЛ.*** 2 аш кашыгы каен бөресенә 70 грамм атланмай кушып, ут өстендә эретегез. Әмма кайнатырга ярамый. Ут өстендә яки духовкада сәгатькә якын торсын. Каен бөресен җылы көенчә сыгып алып ташлагыз. Ә сыеклык өстенә 200 грамм бал өстәгез. Шуны көнгә 4 тапкыр берәр аш кашыгы эчегез.

***ТӨНГЕ ЮТӘЛ.*** Йокы алдыннан бер аш кашыгы атланмай йотыгыз. Аннары, ашыкмыйча гына, 1 аш кашыгы бал ашагыз. Артыннан су да, башка сыеклык та эчәргә кирәкми.

***КУЕ КАКЫРЫК.*** Тын юлларын чистарту өчен бака яфрагына бал кушып ясалган төнәтмә эчегез. Моның өчен 3 аш кашыгы яшел яфрак өстенә 3 кашык бал һәм су өстәп, 4 сәгатькә җылы плитә өстенә куегыз. Шул төнәтмәне ашар алдыннан ярты сәгать кала көнгә 4 тапкыр эчегез. Кипкән яфрак булса, 1 стакан суга 1 аш кашыгы яфрак салып, 2 сәгать төнәтегез. Аннары шуны сөзеп алып, 1 аш кашыгы бал кушыгыз. Көнгә 4 тапкыр, ашарга 20 минут кала, берәр аш кашыгы эчегез.

***ТАМАК АВЫРТКАНДА.*** Мүк җиләге, кызыл чөгендер согы, бал һәм аракыны бертигез күләмдә алып, 3 көнгә төнәтмә ясарга куегыз. Шуны көнгә 3 - 4 тапкыр, ашарга бер сәгать кала, берәр аш кашыгы эчегез.

Ярты стакан кишер согына бер аш кашыгы бал кушып болгатыгыз. Шушы кушылмага бергә - бер исәбеннән кайнаган җылы су өстәгез һәм шул сыеклык белән көнгә берничә тапкыр тамагыгызны чайкатыгыз. Тамак авыртканда сары мәтрүшкә белән прополис катнашмасыннан ясалган төнәтмәне эчү дә бик файдалы. Бер аш кашыгы үлән өстенә бер стакан кайнар су салып, 20 минут тотарга һәм аннары, шуны сөзеп алып, тамакны чайкатырга кирәк. Бер тапкыр чайкату өчен ярты стакан төнәтмә җитә. Шуның өстенә 20 тамчы прополис төнәтмәсе тамызып, көнгә 2 - 3 тапкыр чайкатыгыз.

***САЛКЫН ТИЕП, БОРЫННАН СУ АККАНДА.*** 100 грамм чөгендер суында 30 грамм бал эретегез. Шуны көнгә 4 - 5 тапкыр һәр борын тишегенә 5 - 6 тамчы тамызыгыз.

Болай дәвалау бигрәк тә балалар өчен бик шифалы. Бу тамчылар, әлбәттә, баланы аденоидлардан коткармаячак, әмма сулыш алуын җиңеләйтәчәк.

***ГАЙМОРИТ, СИНУСИТ.*** Бу авырудан котылуда сезгә кәрәзле бал ярдәм итәчәк. 4 - 6 сәгать дәвамында сәгатенә унбишәр минут кәрәзле бал ашап, кәрәзен чәйнәп торыгыз. Көн ахырына кадәр борыныгыз иркен сулый башлар, авыртуы басылыр. Аннары бер атна буена кәрәзле балны көнгә бер тапкыр ашарга, чәйнәргә кирәк.

Белгечләр бу авырудан саклану өчен, гомумән, көз көннәреннән алып җәйгә кадәр, көн саен 1 - 2 чәй калагы бал кабып, кәрәзен озак чәйнәргә киңәш итәләр. Шулай итеп, саклану чарасын алдан күргәндә, гайморит һәм борыннан су килү гадәтеннән котылырга мөмкин.

**(«Здоровье» журналыннан алынды).**

# *Кемнәр - көтә, кемнәр - сата...*

***«Татарстан исемле хосусыйлаштыру кертемен «Норлатсервистехинвест» хосусыйлаштыру фондына тапшырган идем. Дивидендларны бик мулдан вәгъдә итсәләр дә сүзләре буш куык кына булды, ахрысы, бернинди дивиденд та алганым юк. Зинһар, белешегез, безне шулай ук төп башына утырттылар микәнни?!***

***М.Ишмаева».***

Кара Күл авылыннан М.Ишмаева хаты буенча инвестиция фондында түбәндәгеләр мәгълүм булды.

Фонд үзенең әгъзаларына 1993, 1994 еллар өчен 100 процент күләмендә дивиденд түләгән булган. Мингайшә Ишмаева, бәхетсезлегенә каршы, ИПКсын 1995 елның маенда гына тапшырган булган. Ә акционерларның гомуми җыелышы, табыш аз булу сәбәпле, 1995 ел өчен дивиденд түләмәскә, табышны ары таба үстерүгә юнәлтергә дигән карар кабул итә. Шунлыктан, Мингайшә ханым, сез дивиденд ала алмагансыз. Әмма күңелегезне төшермәгез, сез ялгыз түгел, сездән кала тагын фондның 12006 членының акча күрергә дигән өметләре җилгә очты. 1996 нчы ел нәтиҗәләре буенча җыелыш әле 1997 елның июнь аенда гына булачак, шунлыктан сезгә быел да дивиденд күрү насыйп булыр дип кистереп әйтергә иртәрәк. Әмма бер ысул тәкъдим итә алабыз «Сервистехинвест» теләгән членнарыннан акцияләрне сатып ала. Бер акция бәясе 1300 сум, шул рәвешле сез 64 акциягезне фондка сатып, төп - төгәл 83200 сум акча «эшли» аласыз. Фонд хезмәткәрләре әйтүенә караганда, өметләре өзелгән авыл акционерлары арасында андыйлар бар икән. Ә күпләр әлегә көтә. Бәлки сез дә тагын 1 - 2 ел сабыр итеп карарсыз?

# *КОТЛЫЙБЫЗ!*

*Киекле авылында яшәүче кадерле әниебез, зур әниебез **Фатыйма Галиевага** шушы көннәрдә 70 яшь тула.*

*Бу көннәрдә синең юбилееӊ,*
*Чын күңелдән сине котлыйбыз.*
*Киләчәккә шатлык, саулык белән,*
*Тыныч тормыш теләп калабыз.*
*Син бит әниебез безнең өчен,*
*Күпме кайгы - шатлык кичердеӊ*
*Без аякка басып кеше булсын диеп*
*Сөеп, назлап, сыйпап үстердеӊ.*

***Изге теләкләр белән балаларың, кияүләрең, киленнәрең, оныкларың.***



## белдерүләр

### Сатабыз

**Буе 6 метрлы, калынлыгы 4 - 5 сантиметрлы 15 кубик метр ылыслы агач такталары.** Тел.: 5 - 27 - 41, 5 - 11 - 44.

***

**ВАЗ - 2107гә яңа кузов, эретеп ябыштыру аппараты, газ колонкасы.** Погрузная станциясе, Заводская ур., 76 адресы буенча Исмәгыйловка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Кирпеч гараж.** Адрес: Нефтьчеләр ур., 6 - 25 (кичке 6дан соң).

***

**Ашыгыч төстә ВАЗ - 2106.**
Адрес: Октябрьская ур., 91 - 9.

***

**НГДУ ЖКХсы каршында гараж.** Адрес: Дружба ур., 60 - 13 (кичке 5 тән соң).

***

**11,5 миллионга 1991 елгы ВАЗ - 2105**.
Тел.: 5 - 21 - 94.

### Алмаштырабыз

**Шәхси йортны ашыгыч төстә - өстәмә түләп бер бүлмәле фатирга.** Адрес: Маяковский ур., 1.

***

**Юрий Николаевич Прокопцев исеменә бирелгән шофер таныклыгын табучы булса бүләк бәрабәренә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Тел.: 2 - 20 - 17.

### Табылдыклар өстәле

**Такса көчеге югалтучы кичке 6 дан соң 5 - 22 - 88 номеры белән шалтырата ала.**

***

**Финанс хәлегезне яхшыртырга теләмисезме?**

Сез үзегез өчен уңайлы вакытта бездә эшләп ала аласыз. Кыюлыгыгызны җыегыз да һәр чәршәмбе көнне кичке 6да мәгълүмат алу өчен район үзәк китапханәсенең уку залына килегез.

***

**Кешечә генә процент белән кредитка акча алабыз**. Телефон: 2 - 18 - 16 (кичке 5тән 9га кадәр).

Ире үлү сәбәпле, Нажия ханым Гыйматдинованың кайгысын уртаклашам.

Хатирә Вәлиева.
Бикүле авылы.

«Дуслык» («Дружба», «Туслах») район газетасы редакциясе һәм Норлат шәһәр типографиясе коллективлары редакциянең элеккеге хезмәткәре **Валентина Алексеевна Пирогованың** кинәт вафат булуын тирән кайгы белән кичерәләр һәм мәрхүмәнең гаиләсенең, туганнарының һәм якыннарының авыр хәсрәтен уртаклашалар.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2047 дана. **Заказ N 5140.**